**Класс**: 6

**Укытучы**: Насыбуллина Резедә Сәйрин кызы

**Программа:** Җәмгыять белеме. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /(Л.Н.Боголюбов һ.б., русчадан Л.Н.Гыймадеева тәрҗемәсе)-Казан: Татар.нәшр., 2020.-160 б.:рәс.б-н.

**Тема**: Кеше - шәхес

1 слайд

Белгәнегезчә, кеше биологик җан иясе булып дөньяга килә һәм социаль (җәмгыяви) зат булып үсә. Кеше булып формалашуның төп шарты – аның кешелек җәмгыятендә яшәве. Гаилә, мәктәп, башта балалар, ә аннары олылар тирәлеге, уен, хезмәт, уку- боларның барысы да балага йогынты ясый, аңарда билгеле бер шәхси сыйфатлар тәрбияли.

2 слайд

Шәхес нәрсә соң ул? Антонио Грамши – XX гасырның танылган итальян философы, сәясәтчесе, җәмгыять эшлеклесе – “Нәрсә ул шәхес?” дигән сорауга җавап бирүче өч позицияне формалаштырган.

“Кеше үз язмышының хуҗасы була аламы?”

“Ул үзен үзе “ясый” аламы?”

“Үзенең шәхси тормышын төзи аламы?”

Нәкъ менә шушы сүзләр шәхескә бәяләмә бирәдер дә.

3 слайд

Психологиядә **шәхес – кешене җәмгыять әгъзасы буларак характерлаучы сыйфатларның тотрыклы системасы дип аңлатыла.** Ул эшчәнлек һәм башкалар белән аралашу барышында үзләштерелә һәм чагылыш таба. Психологлар шәхесне кеше үсешенең иң югары дәрәҗәсе дип атыйлар, чөнки шәхес кенә аңга ия.

4 слайд

“Аң нәрсә соң ул?” дигән сорауга җавап бирик. Моның өчен бу сүзнең мәгънәсен анализлыйк. “Белемле” кеше ниндидер күзаллаулар белән генә чикләнмичә, алган белемнәрен куллана, уйлый, фикерли белә, яңа белемнәр табу ысулларын үзләштерә, үзенең эрудициясенә һәм культурасына тәнкыйть күзлеге аша карый белә. Башка сүзләр белән әйткәндә, аң - кешенең дөньяга мөнәсәбәте, нәрсә эшләвен, ничек яшәвен, ни турында хыяллануын аңлавы ул. Аң кешегә төрле эшчәнлек алып барырга, башка кешеләр белән аралашырга, тирә-юнендәгеләрне һәм үзен бәяләргә мөмкинлек бирә.

5 слайд

Аң кешегә генә хас, шуңа күрә кеше генә шәхес була ала. Ә кайчан кешене шәхес дип әйтеп була? Бу кешенең үз-үзен аңлавы, үзенең “мин”ен башкалардан аеруы белән бәйләнгән. Синең, әлбәттә, бик нәни балаларны күзәткәнең бардыр. Алар, үзләре турында сөйләгәндә, “Әмир”, “малай” дип сөйләшәләр, “мин” алмашлыгын кулланмыйлар. Ниһаять, шундый вакыт җитә, бала үзен башкалардан аера белә башлый, үзен яшьтәшләре белән чагыштыра, үзенчәлекле булуын күрсәтә. Психологлар моны үсеп килүче шәхес билгесе дип исәпли.

6 слайд

Индивидуальлек – начар яисә яхшымы?

Син инде барлык кешеләрдә дә уртак сыйфатлар барлыгын беләсең. Алар билгеле бер төзелешле организмга ия, уйлый, сөйли беләләр һ.б.Әммә шул ук вакытта кешеләр дә төрле. Аларның һәрберсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Кемдер зәңгәр күзле, бөдрә чәчле , шигырьләр яза һәм музыка тыңларга ярата; ә башка берәү бик тынгысыз, актив, шаулы уеннарны, спортны өстен күрә; ә өченче кеше бик оялчан, ялгызлык ярата, иҗат белән шөгыльләнә.

Индивидульлек кешенең уңышлы эшчәнлеккә сәләтен дә билгели. Мәсәлән, рәссамда әйләнә-тирә дөнья объектын образлы күрү, аны график һәм сәнгати күзәллый белү сәләте яхшы үскән була. Конструкторлык эшчәнлеге исә логик фикерләү, схема төзү, күзаллаган объектны кору күнекмәләре кебек башка сәләтләр үсешен таләп итә. Сәләтле, гениаль кешеләрнең индивидуальлеге аерым формага ия була. Мәсәлән, А.С.Пушкин укыган Царское Селоның тел-әдәбият укытучысы үз укучыларына төрле иҗади биремнәр тәкъдим итә торган булган, әммә бары тик булачак шагыйрь генә бу биремне оста итеп башкара алган. Бу аның шигъри иҗатка сәләте, ягни Пушкинның индивидульлеге турында сөйли.

7 слайд

Көчле шәхес нинди ул?

Әгәр син әти-әниеңнән “Кем ул Валерий Брумель” дип сорасаң, аның мәшхүр спортчы булуы һәм дөньяда барысыннан да биегрәк сикерүче турында җавап ишетерсең. Брумель чыгыш ясаганда, бар кеше дә аның яңа рекорд ясавын көтә торган була. Ул Европа, дөнья, Олимпия уеннары чемпионы булуга ирешә, әммә бәлагә юлыга-һәлакәткә элләгә һәм аягын имгәтә. Аягы дөрес ялганмый һәм икенчесеннән кыскарак булып кала. Барысы да Брумельның спорт карьерасы тәмамланды дип исәпли, ә Валерий башкача уйлый. Бик авыр операцияләр, озакка сузылган авыр күнегүләр башлана. Ихтыяр, рух

көче, үҗәтлеге  үзенекен итә: Валерий Брумель спортта кабат югары нәтиҗәләргә ирешә. Ул – көчле шәхес.

**Практик өлеш**.

Кызыклы шәхес булырга өйрәнәбез.

1) Белемнәреңне бает.
2) Белемнәреңне бүлеш.
3) Үзеңнән яхшы нәрсәләр эзлә.
4) Башкаларны тыңла.
5) Синең үзенчәлекләрең- шәхеснең бер өлеше
6) Үзең була бел.
7) Куркып яшәмә.
8) Пессимистлардан качарга тырыш
9) Юмор хисеңне эшкә җик.

**Йомгаклау**